ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 август, 2021 ел № 8/9

Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу яйсә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу яйсә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә (Шәһәр Советының 2019 елның 7 октябрендәге 33/10, 2020 елның 28 маендагы 39/10 номерлы Карарлары редакциясендә), 34 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3) иҗтимагый фикер алышуны яйсә җәмәгать тыңлауларын оештыручы адресына язмача яки электрон документ;».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев